«Раслыйм»

__________________

МАӨББҮ 14 санлы Балалар – яшүсмерләр үзәге директоры Н.Ә.Рәхмәтуллина

«Нәфис сүз остасы» бәйгесе Нигезнамәсе

**Бәйгене үткәрү максаты һәм бурычлары**

Бәйге укучыларның татар әдәбияты белән кызыксынуын арттыру, татар телен тирәнтен үзләштерү, сәнгатьле сөйләм күнекмәләрен булдыру, сәләтле балаларны барлау , милли тәрбия бирү максатыннан үткәрелә.

**Бәйгене үткәрү тәртибе**

«Нәфис сүз остасы» бәйгесе 2 турда үткәрелә:

1 нче тур - белем бирү учреждениеләренең еллык планы нигезендә 1-11 сыйныф укучылары арасында;

2 нче тур - мәктәптә җиңгән укучылар арасында район күләмендә үткәрелә .

**Бәйгедә катнашу тәртибе:**

Бәйгегә һәр мәктәп бик яхшы әзерлекле 2 укучы җибәрә. 1 укучы татар, 1 укучы рус милләтеннән.

Бәйгедә катнашучы балалар Габдулла Тукай иҗатыннан 1 әсәр әзерли.:

**Бәяләү критерийлары**

- Дикция, интонация, уку сәнгатьлелеге;
- Образга керү дәрәҗәсе;
- Сөйләүченең гәүдә торышы, хәрәкәте, мимикасы;
- Сөйләү темпының эчтәлеккә туры килүе;

Һәр пункт 5 балл системасында бәяләнә. Гомуми балл-20.

Искәрмә: жюри тарафыннан критерийлар тулыландырырга мөмкин.

**Оештыру комитеты һәм жюриның хокуклары һәм бурычлары:**

- Жюри критерийлар нигезендә гадел бәяли.
- Бәйге барышында жюри эшчәнлегенә комачаулау, укучылар алдында килешмәүне белдерүгә юл куелмый.
- Бәйгене оештыру, үткәрү, бәяләү критерийларына таләпләр буенча тәнкыйть һәм тәкъдим язма рәвештә оештыру комиссиясенә тапшырыла.
- Оештыру һәм үткәрү процессын камилләштерү максатыннан комиссия барлык фикерләрне өйрәнергә һәм киләчәктә гамәлгә ашырырга бурычлы.

Бәйге Үзәк районы мәктәпләре өчен:

16.04.2021, 13.00, 14 санлы Балалар һәм яшүсмерләр үзәге , **Яңа шәһәр, 44/16**

**Телефон: 89172416676**

Үзәк районы мәктәпләренә бәйгедә катнашу өчен түбәндәге формада 14.04.2021 хәтле заявка җибәрү сорала (akhmetova.farida@inbox.ru) :

| Мәктәп саны, сыйныфы | Укучының исем-фамилиясе | Җитәкченең исем-фамилиясе, электрон адресы | Башкарылачак әсәр | Элемтә өчен телефон. |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |